ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

13.09.2016 БОЕРЫК № 069-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсен үзгәртеп кору мәсьәләләре” 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре” 2016 елның 9 августындагы 541 номерлы карары чыгарылуга бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.

2. Хокук һәм кадрлар эше бүлеге башлыгы В.Г. Минниәхмәтовага әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве узуын тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау турында” 2014 елның 10 декабрендәге 092 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының Архив эше
буенча дәүләт комитетының
2016 елның 13 сентябрендәге
069-од номерлы боерыгына
Кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТҮГӘ) КОНКУРС ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) составы, аның эшләү сроклары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү методикасы билгеләнә.

1.2. Нигезләмә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында (алга таба – Дәүләт комитеты) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү тәртибен һәм шартларын билгели. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә керүгә булган тигез конституциячел хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә булган хокукын тәэмин итә.

1.3. Дәүләт комитетында конкурс «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы (алга таба – 79-ФЗ номерлы Федераль закон), Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы (алга таба – 112 номерлы Указ), «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервы турындагы нигезләмәне раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы Указы, нигезендә уздырыла.

Конкурс Дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә дагъва итүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен, аларның Татарстан

Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына карата билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүләрен бәяләүдән гыйбарәт.

1.4. Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс 79-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә конкурс нигезендә биләнә торган вакантлы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булганда Дәүләт комитеты рәисе карары белән игълан ителә.

Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертүгә конкурс хокук һәм кадрлар эше бүлеге тарафыннан ел саен башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен белгечләргә Дәүләт комитетының ихтимал ихтыяҗын бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертүгә конкурс әлеге нигезләмәдә каралган тәртиптә Дәүләт комитетының конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

1.5. Конкурсны үткәрү турында карар Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан структур бүлекчә җитәкчесе әзерләгән язма нигезләнгән гаризага (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта) нигезләнеп кабул ителә. Гаризада конкурс игълан итү турында тәкъдим белән беррәттән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы (алга таба – граждан хезмәте вазыйфасы) исеме һәм әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва итүчегә вазыйфа бурычлары үзенчәлекләрен исәпкә алып куела торган таләпләр күрсәтелергә тиеш.

1.6. Дәүләт комитетында конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

а) Дәүләт комитетында «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләре граждан хезмәте вазыйфаларын вәкаләтләрнең билгеле бер срогында биләүгә билгеләнгәндә;

б) вакытлы хезмәт контракты төзелгәндә;

в) 79-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1 өлешендә һәм 60.1 статьясындагы 9 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләнгәндә;

г) граждан хезмәте вазыйфасына граждан хезмәтенә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәре (граждан) билгеләнгәндә;

д) билгеләнү һәм азат ителү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган “җитәкчеләр” категориясе граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә.

1.7. Конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

а) вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләрдән файдалану белән бәйле булган, исемлеге Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана торган аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләнгәндә;

б) граждан хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфасына эш бирүче вәкиле карары буенча билгеләнгәндә.

1.8. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

Россия Федерациясе гражданнарының аларның сәләтенә һәм һөнәри әзерлегенә ярашлы рәвештә дәүләт граждан хезмәтенә бертигез дәрәҗәдә керү мөмкинлегенә конституциячел хокукларын тәэмин итү, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәренең конкурс нигезенда вазыйфаи үсешкә хокукларын тәэмин итү;

федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һам Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килүче һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар арасыннан вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен иң туры килүче кандидатларны сайлап алу;

Дәүләт комитетының кадрлар резервын булдыру.

1.9. Конкурсларны үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәүдә барлык кандидатлар өчен тигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны объектив һөнәри әһәмиятле критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән конкурста катнашучылар арасыннан вакантлы граждан хезмәте вазыйфалары таләпләренә туры килүче затларны билгеләү.

## II. КОНКУРС КОМИССИЯСЕН ТӨЗҮ ҺӘМ АНЫҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

2.1. Дәүләт комитетында конкурс үткәрү өчен Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясенең составы Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның персональ составы үзгәргәндә, Дәүләт комитеты боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан гыйбарәт.

2.2.1. Дәүләт комитетында чикләнмәгән срокка “җитәкчеләр” категориясе вакантлы граждан хезмәте вазыйфасына конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясен Дәүләт комитеты рәисе җитәкчелек итә.

2.2.2. Граждан хезмәтенең башка вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар үткәрү өчен Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән граждан хезмәте вазыйфаларының төрле категорияләре һәм төркемнәре өчен берничә конкурс комиссиясе төзелергә мөмкин.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырыш уздыру датасын билгели һәм аның көн тәртибен раслый, комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларга кул куя. Комиссия рәисе булмаганда, аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе рәисе конкурс процедураларын әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем составын раслый.

Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны теркәү, кабул итү, делолар булдыру, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү).

2.4. Конкурс комиссиясе составына Дәүләт комитеты рәисе, аның урынбасарлары һәм (яки) ул вәкаләт биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән хокук һәм кадрлар эше бүлегеннән һәм Дәүләт комитетының вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәсеннән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт

хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук Дәүләт комитеты соратуы буенча граждан хезмәте белән бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез эксперт-белгечләр сыйфатында, экспертларның шәхси мәгълүматлары күрсәтелмичә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакырыла торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре керә. Конкурс комиссиясе составына кертү өчен Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары әлеге совет тарафыннан Дәүләт комитеты рәисе соратуы буенча тәкъдим ителә.

Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалану вазыйфаи бурычларына кертелгән граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе кабул итә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу ихтималы булмаслык итеп төзелергә тиеш.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертүгә) кименда ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын Дәүләт комитетында граждан хезмәте вазыйфаларын били торган комиссия әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

конкурс үткәрү шартларын регламентлаштыра торган документларны, аны үткәрү өчен кирәкле методик һәм башка материалларны раслау турында;

конкурс үткәрү план-графигын раслау турында;

конкурс йомгакларын чыгару турында;

конкурс процедураларын үткәрү нәтиҗәләре буенча төзелгән рейтингта беренче урынны алган кандидатларны конкурсның җиңүчеләре дип тану турында;

Татарстан Республикасы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен Дәүләт комитетының кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатлар исемлекләрен төзү турында.

2.9. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белан аның утырышта катнашкан агъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора. Конкурс комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы, кабул ителгән карар белән килешмәсә, үз фикерен белдерә ала, ул комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә һәм конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы имзасы белән беркетелә.

2.10. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары кандидат булмаганда кабул ителә һәм аны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү йә мондый билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе шулай ук граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын

биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс җиңүчесе булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган, кандидатны Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертү турында тәкъдим буларак карар кабул итәргә хокуклы. Күрсәтелгән кандидат ризалыгы белән ул Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертелергә мөмкин.

2.11. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта), ул рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

2.12. Конкурс процедурасын билгеләү һәм әзерләү буенча эш документларының, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләре эчтәлеге, конкурс биремнәре сораулары һәм темалары исемлеге конкурс тәгәлләнгәнче хезмәттә файдалану өчен булган мәгълүмат булып тора.

2.13. Конкурсны турыдан-туры оештыруны һәм аны үткәрүне тәэмин итүне, конкурс комиссиясе эшен хокук һәм кадрлар эше бүлеге башкара.

## III. КОНКУРСНЫҢ КАТНАШУЧЫЛАРЫ

3.1. Конкурста катнашуга Дәүләт комитеты граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дагъва итүче кандидатларга карата тиешле таләпләргә туры килә торган һәм әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында каралган срокта барлык кирәкле документларны тапшырган гражданнар (алга таба – кандидатлар) кертелә.

Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларга карата таләпләр (әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта) һәм Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тапшыра торган документлар һәм материаллар исемлеге (әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымта) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.2. Конкурста катнашу өчен документлар Дәүләт комитетына кандидатлар тарафыннан Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталында (алга таба – Дәүләт комитетының рәсми сайты) конкурс үткәрелү турында мәгълүмати белдерү урнаштырылган көннән алып 21 көн эчендә тапшырыла. Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тапшыра торган документлар һәм материаллар исемлеге 4 нче кушымтада бирелгән.

3.3. Документларның вакытында тапшырылмавы, аларның тулы булмаган күләмдә яки җитди сәбәпсез рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырылуы гражданга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

3.4. Дәүләт комитетының конкурста катнашырга теләк белдергән граждан хезмәткәре Дәүләт комитеты рәисе исеменә гариза яза.

3.5. Конкурста катнашырга теләк белдергән бүтән дәүләт органында вазыйфа биләүче граждан хезмәткәре Дәүләт комитетына Дәүләт комитеты рәисе исеменә шәхси гариза һәм үз кулы белән тутырылган, граждан хезмәткәре граждан хезмәте

вазыйфасын биләгән дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан имзаланган һәм таныкланган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган форма буенча анкетаны фотосурәтләре (4*6, почмаксыз) белән бергә тапшыра.

3.6. Граждан (граждан хезмәткәре) ризалыгы белән, әгәр граждан (граждан хезмәткәре) дәгъва итә торган граждан хезмәте вазыйфасының вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән белешмәләрдән файдалану белән бәйле булса, аңа мондый белешмәләрне алуга рөхсәт рәсмиләштерү процедурасы башкарыла.

Граждан тарафыннан Дәүләт комитеты рәисе исеменә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш.

Граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү аның Дәүләт комитетында граждан хезмәте вазыйфаларының югары төркменә керә торган граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашу очрагында гына башкарыла.

3.7. Граждан (граждан хезмәткәре), әгәр ул граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына карата куелган квалификация таләпләренә туры килмәсә, шулай ук граждан хезмәтенә керү һәм аны узу өчен дәүләт граждан хезмәте турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашуга кертелми.

## IV. КОНКУРСНЫ ҮТКӘРҮ МЕТОДИКАСЫ

4.1. Конкурс үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе һам Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган ысулларына нигезләнгән конкурс биремнәре һам процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары Дәүләт комитетының граждан хезмәте вазыйфаларына карата куела торган квалификация таләпларе нигезендә эшләнгән.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийларының якынча исемлеге һәм кыскача тасвирламасы әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымтада бирелгән.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары конкурс үткәрелә торган вазыйфаларның төркеменә һәм категориясенә бәйле рәвештә үзгәртелергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һам сайлап алу алар тарафыннан үтәлгән конкурс биремнәре һам конкурс процедураларын үтәү нәтиҗәләре нигезендә хәл ителә.

Нәтиҗәләр кандидатлар исемлеген баллар буенча ранжирлау (рейтинг) рәвешендә чыгарыла.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтларында конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла: граждан

хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервы булдырыла торган вазыйфа) исеме, бу вазыйфаны биләүгә дәгъва итүчегә карата куела торган таләпләр, граждан хезмәтен узу шартлары, Дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итү тәгалләнү срогы, конкурсны үткәрүнең якынча датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар.

Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан һәм конкурс турында мәгълүмат шулай ук вакытлы басма матбугатта бастырыла ала.

Конкурсның беренче этабы Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтларында йә вакытлы басма матбугатта конкурс үткәрелү турында мәгълүмати хәбәр урнаштырылган көннән башлана һәм кимендә 21 көннән соң тәгалләнә.

4.4.2. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва итүчеләр тарафыннан тапшырылган документлар тикшерелгәннән, Дәүләт комитеты кадрлар резервына кертелгәннән соң, хокук һәм кадрлар эше бүлеге гражданнарны (граждан хезмәткәрен) конкурста катнашуга кертү турында йә аларны конкурста катнашуга кертүдән нигезләнгән баш тарту турында карар кабул итү өчен Дәүләт комитеты рәисенә тәкъдим кертә.

Дәгъва итүчеләрнең тикшерелгән документлары һәм хокук һәм кадрлар эше бүлеге тәкъдиме конкурсның икенче этабын үткәрү турында карар кабул итү өчен Дәүләт комитеты рәисенә кертелә.

4.4.3. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә каршылык тудыра торган сәбәпләр ачыкланган очракта, аңа хокук һәм кадрлар эше бүлеге конкурста катнашуга кертелмәү сәбәпләре турында язма равештә хәбәр итә.

4.4.4. Конкурста катнашуга кертелмаган Дәүләт комитетында вакантлы вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва итүче бу submit карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы тәгалләнү шарты булып Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасына) билгеләнгән таләпларгә туры килә торган кимендә ике кандидатның булуы кирәк, бу кандидатларны алга таба сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Хокук һәм кадрлар эше бүлеге конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 көн кала конкурста катнашуга үткәрелгән гражданнарга (граждан хезмәткәренә) аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр җибәрә.

Вазыйфага карата квалификация таләпләрен канәгатьләндерә торган кандидатлар булмаган яки бер генә кандидат булган очракта, конкурс үткәрелмәгән

дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка конкурс комиссиясе карары белән конкурсның, кандидатларның таләп ителгән саны булмаганга күрә, үтмәгән дип танылуы турында язмача хәбәр ителә.

4.4.6. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр башкарыла:

а) конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һам шәхси сыйфатларын бәяли;

б) Дәүләт комитеты рәисе Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс җиңүчесен билгеләү турында карар кабул итә.

4.4.7. Конкурсны үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларны белемнәре, граждан яки башка дәүләт хезмәтендә булулары, башка төрле хезмәт эшчанлеге башкарулары турында алар тарафыннан тапшырылган документларга, шулай ук кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган алымнарын, шул исәптән Дәүләт комитетында кандидатлар биләүгә дәгъва итә торган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы) вазыйфаи бурычларын үтәү белән бәйле сораулар буенча тест һәм индивидуаль әңгәмә кулланылган конкурс процедураларына нигезләнеп бәяли.

4.4.8. Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең төгәл вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасына) кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы даулат граждан хезмәткарларен, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белан расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарга тест уздыру методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4.9. Тест узган кандидатлар белән индивидуаль әңгәмәне конкурс комиссиясе әгъзалары үткәрә.

Индивидуаль әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бирелә торган кандидатларның булачак һөнәри хезмәт эшчәнлекләренә караган сорауларга телдән җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе граждан хезмәте вазыйфасына квалификация таләпләреннән һәм бу вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук әлеге Нигезләмә һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Ресубликасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарының башка нигезләмәләреннән чыгып кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяли.

4.5. Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән конкурс комиссиясе карары конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.6. Конкурс нәтиҗәләрен чыгару һәм Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидат турында карар кабул итү өчен кандидатлар җыйган тавышлар саны, кандидатлар дагъва итә торган вазыйфаның структур булекчәсе җитәкчесе фикере нигез була.

“Әйе” тавышын иң күп җыйган кандидат конкурс җиңүчесе дип таныла.

Иң күп балларның тигез санын конкурсның бер яки аннан күбрәк катнашучысы җыйган очракта, конкурс комиссиясе рәисе фикере хәлиткеч була.

4.7. Әгәр конкурс үткәрү нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирүче кандидатлар билгеләнмәгәндә, конкурс комиссиясе өстама конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа конкурс үткәрү турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.8. Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына конкурс җиңүчесен билгеләү турында Дәүләт комитеты боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Әгәр конкурс комиссиясе граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурсның җиңүчесе булмаган кандидатны Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертү турында карар кабул итсә, күрсәтелгән зат ризалыгы белән аны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы кергән шул ук төркемнең граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен шул органның кадрлар резервына кертү турында Дәүләт комитеты боерыгы чыгарыла.

Конкурсның җиңүчесен вазыйфага билгеләү тәкъдим ителгәндә, Дәүләт комитеты рәисенә мәҗбүри рәвештә конкурс комиссиясе карары һәм комиссия тарафыннан мондый карар кабул ителү өчен нигез булган материаллар күрсәтелә.

4.9. Конкурста катнашкан кандидатларга хокук һәм кадрлар эше бүлеге конкурс нәтиҗәләре турында конкурс тамамланган көннән соң җиде көн эчендә язмача хәбәр юллый.

Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтарендә Дәүләт комитетының расми сайтына һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасына урнаштырыла.

4.10. Конкурста катнашуга үткәрелмәгән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва итүчеләрнең һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары аларга язма гариза буенча конкурс төгәлләнгән көннән алып өч ел эчендә кире кайтарылырга мөмкин.

4.11. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм аннан кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемта чаралары хезмәт күрсәтүләреннән файдалану һәм башкалар) кандидатларның үз акчалары хисабына башкарыла.

4.12. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

Татарстан Республикасының Архив эше
буенча дәүләт комитетының 2016 елның
13 сентябрендәге 069-од номерлы
боерыгы белән расланган Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасының Архив эше
буенча дәүләт комитеты рәисенә

________________________
(инициаллары, фамилиясе)

ГАРИЗА

Сездән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс игълан итүегезне сорыйм.

__________________________________________________________
(вазыйфа исеме)

__________________________________________________________
(бүлек исеме)

Әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва итүчегә карата түбәндәге таләпләр куела:

__________________________________________________________

__________________________________________________________

__________________________________________________________
(таләпләрне санап үтәргә)

Кушымта: Вазыйфа регламенты күчермәсе.

______________________ ______________ ________________________________
(били торган вазыйфа) (имза) (фамилия һәм инициаллар)

Дата

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт комитеты
рәисе урынбасары

______________________ ________________________________
(имза, дата) (фамилия һәм инициаллар)

Татарстан Республикасының Архив эше
буенча дәүләт комитетының 2016 елның
13 сентябрендәге 069-од номерлы
боерыгы белән расланган Нигезләмәгә
2 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫНЫҢ КОНКУРС КОМИССИЯСЕ УТЫРЫШЫ БЕРКЕТМӘСЕ
№_________

Казан ш. ______________
Дата

Рәис:_________________
Конкурс комиссиясе
рәисе урынбасары _____________________
Конкурс комиссиясе секретаре____________________
Конкурс комиссиясе әгъзалары_________________________________

Тиешле кворум бар.

Көн тәртибе:

_______________________
Тыңланды:
_____________________________________
Чыгыш ясадылар:
_____________________________________
Карар чыгарылды:
_____________________________________

Рәис: _________________________________
Конкурс комиссиясе
рәисе урынбасары _________________________________
Конкурс комиссиясе секретаре _________________________________
Конкурс комиссиясе әгъзалары _________________________________

Татарстан Республикасының Архив эше
буенча дәүләт комитетының 2016 елның
13 сентябрендәге 069-од номерлы
боерыгы белән расланган Нигезләмәгә
3 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАЛАРЫН БИЛӘҮГӘ (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТҮГӘ) КАНДИДАТЛАРГА КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

## I. ГОМУМИ ТАЛӘПЛӘР

1.1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашырга 18 яше тулган, Россия Федерациясе дәүләт телен белгән, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын) биләү өчен кирәкле Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүче Россия Федерациясе гражданнары хокуклы.

Граждан хезмәткәре Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста гомуми нигезләр буенча катнашырга хокуклы.

1.2. Граждан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашуга, әгәр ул Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына карата куелган квалификация таләпләренә туры килмәсә, шулай ук граждан хезмәтенә керү һәм аны узу өчен дәүләт граждан хезмәте турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә кертелми.

## II. КВАЛИФИКАЦИЯ ТАЛӘПЛӘРЕ

2.1. Белемгә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте стажына яки эш (хезмәт) стажына карата квалификация таләпләре:

барлык категориядәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең баш вазыйфалары – югары һөнәри белем, әйдәүче һәм өлкән төркем дәүләт хезмәте вазыйфаларында кимендә ике ел дәүләт хезмәте стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә өч ел эш стажы булу;

барлык категориядәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәүче вазыйфалары – югары һөнәри белем, өлкән һәм кече төркем дәүләт хезмәте вазыйфаларында кимендә бер ел дәүләт хезмәте стажы яки белгечлек, әзерлек

юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы булу;

“белгечләр” категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалары – стажга карата таләпләрсез югары һөнәри белем булу;

“тәэмин итүче белгечләр” категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалары – стажга карата таләпләрсез эшчәнлек юнәлеше буенча урта һөнәри белем булу;

дәүләт хезмәтенең кече вазыйфалары – стажга карата таләпләрсез эшчәнлек юнәлеше буенча урта һөнәри белем булу.

2.2. Вазыйфа бурычларын үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәргә һәм тәҗрибәгә карата квалификация таләпләре Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәренең вазыйфа регламентында билгеләнгән.

Татарстан Республикасының Архив эше
буенча дәүләт комитетының 2016 елның
13 сентябрендәге 069-од номерлы
боерыгы белән расланган Нигезләмәгә
4 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАЛАРЫН БИЛӘҮГӘ (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТҮГӘ) КАНДИДАТЛАР ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы Дәүләт комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза (әлеге Исемлеккә кушымта);

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган форма буенча үз кулы белан тутырылган һам имзаланган, ике фотосурәт (4х6 см.) беркетелгән анкета;

в) паспорты яки аны алыштыручы документның күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

г) кирәкле һөнәри белемен, квалификациясен һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең нотариуста яки эш (хезмәт) урынында кадрлар хезмәте тарафыннан расланган күчермәсе (эш (хезмәт) эшчәнлеге беренче мәртәбә башкарыла торган очраклардан гайре) яисә гражданның хезмәт эшчәнлеген раслый торган бүтән документлар;

белеме һәм квалификациясе турындагы документларның күчермәләре, шулай ук граждан теләге буенча — өстәмә һөнәри белем алу яки белем күтәрү нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрелүне яки бирелүне раслый торган документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турындагы документларның нотариуста яки эш (хезмәт) урынында кадрлар хезмәте тарафыннан расланган күчермәләре;

д) гражданның граждан хезмәтенә керергә яисә аны узарга каршы килә торган авыруы булмавы турында документ, аның формасы Россия Саламатлек саклау һам социаль үсеш министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белан расланган;

е) «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган бүтән документлар.

Татарстан Республикасының Архив эше
буенча дәүләт дәүләт комитетында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан
хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын
биләүгә (кадрлар резервына кертүгә)
кандидатлар тарафыннан тапшырыла
торган документлар һәм материаллар
исемлегенә
кушымта

Татарстан Республикасының Архив эше
буенча дәүләт комитеты рәисенә
__________________________
(Ф.И.А.и.)

Яшәү урыны________________________
Туу елы__________________________
Белем__________________________
Адрес__________________________
Тел.:__________________________
(эш, өй, мобиль)
E-mail:________________________

ГАРИЗА

Мине Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) вакантлы

__________________________________________________________
(вазыйфа атамасы)

вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурсында катнашуга кертүегезне сорыйм:

«Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервы турындагы нигезләмәне раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы Указы, Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә, шул исәптән күрсәтелгән вазыйфага карата куелган квалификация таләпләре белән таныштым.

Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән белешмәләрне алуга рөхсәт рәсмиләштерү процедурасын үткәрүгә ризалык бирәм.

Конкурс уздыру датасы һәм урыны турында E-mail аша яки күрсәтелгән мобиль телефон номерына смс-хәбәр җибәреп хәбәр итәргә ризалык бирәм.

Гаризага * кушып бирәм: (кушып бирелә торган документларны санап чыгарга)

__________________________________________________________

“___” ______________, 20____ ел ________________ ___________________________
(имза) (имзаны аңлатып язу)

* Гариза кулъязма рәвешендә тутырыла.

Татарстан Республикасының Архив эше
буенча дәүләт комитетының 2016 елның
13 сентябрендәге 069-од номерлы
боерыгы белән расланган Нигезләмәгә
5 нче кушымта

# КОНКУРСТА КАТНАШУЧЫЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

## I. ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КУЛЬТУРАСЫНА ТУРЫ КИЛҮ

1.1. Һөнәри мотивация

Дәүләт хезмәтендә һөнәри яктан үзеңне табарга омтылу, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәт урынында үсү турында уйлау.

1.2. Гражданлык позициясе.

Эшчәнлектә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итү принципларына тугры калу, законнарны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен үтәү.

1.3. Һөнәри яктан активлык.

Куелган бурычларны хәл иткәндә инициатива белдерергә омтыла; ирешергә мөмкин булган иң яхшы нәтиҗәне алу өчен күп көч куярга әзер булу; физик һәм эмоциональ йөкләнеш шартларында нәтиҗәле эшли алу (стресска бирешмәүчәнлек).

1.4. Үз-үзеңне үстерергә әзерлек.

Үз белемен, күнекмәләрен камилләштерүгә, күпкырлылыкны киңәйтергә, чиктәш һөнәр өлкәләрендә белем һәм тәҗрибә алырга даими омтылу.

## II. ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТКӘРЕНЕҢ ҺӨНӘРИ КОМПЕТЕНТЛЫГЫ

2.1. Белем дәрәҗәсе.

Төп һәм өстәмә һөнәри белем дәрәҗәсе, профиле һәм сыйфаты.

2.2. Һөнәри тәҗрибә.

Тиешле һөнәр өлкәсендә эшчәнлекнең дәвамлылыгы һәм үзенчәлекләре; һөнәри эшчәнлектә төгәл нәтиҗәләргә ирешү; карьера үзенчәлекләре.

2.3. Махсус һөнәри белемнәр, күнекмәләр.

Функциональ бурычларны нәтиҗәле башкарырга мөмкинлек бирә торган тиешле өлкәдәге һөнәри белемнәр дәрәҗәсе; һөнәри эшчәнлекне регламентлаштыра торган Россия Федерациясе законнарын белү, заманча һөнәри технологияләрне белү.

2.4. Гомуми күнекмәләр.

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелегенарттыра торган күнекмәләргә ия булу дәрәҗәсе (компьютерда эшли алу, гомуми грамоталык, чит телләр белү һ.б.ш.).

## III. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТКӘРЕНЕҢ ШӘХСИ-ЭШЛЕКЛЕЛЕК СЫЙФАТЛАРЫ

3.1. Аналитикага сәләт.

Мәгълүматны анализлау һәм структурлаштыруны таләп итә торган катлаулы бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирә торган фикерләүдәге системалылык һәм

яраклашу дәрәҗәсе; яңа, стандарт булмаган юллар таба белү.

3.2. Нәтиҗәле коммуникация күнекмәләре

Эшлекле аралашу этикасын саклау; үз фикереңне нигезләп яклый һәм аппонентларны ышандыра алу, эшлекле сөйләшүләр алып бару күнекмәләре булу.

3.3. Җаваплылык.

Карарлар кабул итүдәге нигезлелек һәм мөстәкыйльлек; нәтиҗәгә ирешүдәә үз өстенә алган йөкләмәләрне үтәргә әзер булу.

3.4. Оештыру сәләте.

Үз эшчәнлеген һәм буйсынган хезмәткәрләр эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, функцияләрне, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлү хисабына нәтиҗәләргә ирешә алу.

Татарстан Республикасының Архив эше
буенча дәүләт комитетының 2016 елның
13 сентябрендәге 069-од номерлы
боерыгы белән расланган Нигезләмәгә
6 нчы кушымта

Кемгә___________________________

Адрес__________________________________

Хөрмәтле ________________________!

Сезгә түбәндәгеләрне хәбәр итәм. Сез Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәтенең _________________________________________(вазыйфаның, бүлекнең исеме) вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурсында катнашуга кертелмисез, чөнки:

(кирәклесен сайларга)

а) граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмисез;

б) граждан хезмәтенә керү һәм аны узу өчен дәүләт граждан хезмәте турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләргә бәйле;

в) документлар вакытында тапшырылмаган (алар тулы булмаган күләмдә яки җитди сәбәпсез рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырылган);

г) тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданның дәүләт граждан хезмәтенә керүенә каршылык тудыра торган шартларның булуы ачыкланды.

Документларны түбәндәге адрес буенча кире кайтара алабыз: 420111, Казан ш., Кремль ур., 2/6 нчы й., Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты, хокук һәм кадрлар эше бүлеге, телефон 292-12-86.

Рәис ____________________________ _____________________________________________

Имза Ф.И.А.и